**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Какре-Елгинского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

423320, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, ул.Советская, д.22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Кәкре-Елга авыл җирлеге
башкарма комитеты

423320, Азнакай районы,
Кәкре-Елга авылы, Совет урамы,
22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29.01. 2016 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» 2015 елның 09 сентябрендәге 16 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында

2010 елның 27 июлендәге Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына таянып, «Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында»2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарына таянып, 26.12.2015 ел, № 109-ТРЗ «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитетының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында»09.09.2015 елгы 16 номерлы карарының 1.11-1.32 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2016 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык И. М. Мөхәммәтҗанов